| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОБИЗЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2018 Яңавыл авылы № 14

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге уставы белән, 2018 елның 18 ноябрендәге 86-14 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында" җирле референдумда кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Яңа Бәзәкә авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче М.М. Ногманов

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Яңа Бәзәкә авыл җирлеге
Башкарма комитетының
29.12.2018 №14
белән расланган

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Яңа Бәзәкә авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1.Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарнң үзара салым акчаларын түләү I һәм II группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылучылардан, ирektән мәхрүм ителгәннәрдән тыш, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан 30.03.2019 вакытка кадәр, аларның җирле референдумда катнашу-катнашмавына һәм аларның тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләреннән бәйсез рәвештә башкарыла.

3. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарына Яңа Бәзәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районы сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгару, шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыру яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

4. Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

5.Гражданнарның үзара салымнан алынган акчалары Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлегенең лицевой (шэхси)счетына күчереләләр.

6. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитеты аша күчерү хокукына ия булган оешма аша күчерү яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

7. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

8. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Яңа Бәзәкә авыл җирлеге
Башкарма комитетының
29.12.2018 №14 карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Яңа Бәзәкә авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № ______

Түләүченең Ф.И.Ә.и. ____________________________________________
Адрес: ____________________________________________
Нигезләмә ____________________________________________
Сезгә __________________________ көнгә кадәрге вакыт эчендә __________________
________________________________чараны гамәлгә ашыру буенча _____ сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:

Кабул итүче як банкы БИК ______________________________
Сч. № ______________________________
Кабул итеп алучы Сч. № ______________________________
ИНН ______________________________
КПП ______________________________
КБК ________________ ОКАТО __________________
Түләүнең билгеләнеше ____________________________________________

Җитәкче __________________ ________________________________________
М.У. (имза) (тулысынча язылыш)

**- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисеп алу сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -**

____________________________________________________________________
(*муниципаль берәмлек исеме*)

бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне _________ сум күләмендә түләү турында № ________ белдерү кәгазе.
Түләүченең Ф.И.Ә.и. ____________________________________________
Адрес: ____________________________________________

Кабул ителде «__ __» ___________ 20__ ел. ________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм _______________ җирлеге башкарма комитетында кала.*